**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.06.2021** **№ 485**

## Муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль эшчәнлеген камилләштерү чаралары планын («юл картасын») раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль эшчәнлеген камилләштерү чаралары планын («юл картасын») (1 нче кушымта) расларга.
2. Муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль эшчәнлеген камилләштерү чаралары планын («юл картасын») гамәлгә ашыру өчен җаваплылыкны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.
3. Муниципаль җир контроле эшен гамәлгә ашыру өчен җаваплылыкны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе С.М. Минһаҗевка йөкләргә.
4. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә муниципаль торак контроле, дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча эшләр башкару өчен җаваплылыкны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.
5. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы
башкарма
комитетының 2021 елның 01
июнендәге 485 номерлы карары белән
расланды

**Муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль эшчәнлеген камилләштерү чаралары планы («юл картасы»)**

| № т/б | Чара | Нәтиҗә | Гамәлгә ашыру срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| Оештыру-методик чаралар | | | | |
| 1. | Муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен раслау | Норматив хокукый акт | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге; Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының Юридик бүлеге |
| 2. | Муниципаль районда гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген раслау | Муниципаль контроль төрләре исемлеге | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге; Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының Юридик бүлеге |
| 3. | Муниципаль контроль төрләре исемлеген алып баруның расланган тәртибен һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген ҖҮО рәсми сайтындагы муниципаль контроль | ҖҮО рәсми сайтында мәгълүмат булу | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Гомуми бүлеге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (дәүләт һәм муниципаль контроль) бүлегендә урнаштыру | | | |
| 4. | Җирле үзидарә органнары тарафыннан контроль астындагы субъектларны (объектларны), муниципаль контроль чаралары нәтиҗәләрен исәпкә алу | Контрольдәге субъектлар (объектлар) исемлеге, муниципаль контроль чаралары нәтиҗәләре буенча белешмәләр булу | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге; Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар | | | | |
| 5. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органы сайтының киңәш ителгән структурасы нигезендә җирле үзидарә органының муниципаль контроль буенча сайт бүлеген тулыландыру һәм вакытында актуальләштерүне тәэмин итү (кушымта) | Җирле үзидарә органының рәсми сайтларында мәгълүмат булу | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Гомуми бүлеге; Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге; Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 6. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларына контрольдә тотуның һәр төре өчен үтәлүләрен бәяләү контроль (күзәтчелек) предматы булган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар исемлеген яисә аларның аерым өлешләрен, шулай ук | Җирле үзидарә органының рәсми сайтларында мәгълүмат булу | Ел дәвамында - законнар таләпләре үзгәргән саен | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Гомуми бүлеге; Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының Юридик бүлеге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тиешле норматив хокукый актлар текстларын урнаштыру | | | |
| 7. | Профилактик чараларның план-графикларын раслау | Расланган план-график | ел саен 20 декабрьгә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге; Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 8. | Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программаларын һәм профилактик чаралар план-графигын ҖҮО рәсми сайтындагы муниципаль контроль бүлегендә (дәүләт һәм муниципаль контроль) урнаштыру | ҖҮО рәсми сайтында мәгълүмат булу | ел саен 30 декабрьгә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Гомуми бүлеге; Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге; Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 9. | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат җиткерү (мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланма эшләү һәм бастырып чыгару, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәрү һәм башка ысуллар белән) | Басмалар, үткәрелгән чаралар | Даими | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Гомуми бүлеге; Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге; Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү күрсәткечләрен раслау | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре исемлеге | Ел дәвамында | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге; Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының Юридик бүлеге |